**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Иске Карамалы авыл җирлегенә керүче Иске Карамалы авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№6** **14.11.2024 ел**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Иске Карамалы авыл җирлегенә керүче
Иске Карамалы авылында узган
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 14 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
Сез, 2025 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Иске Карамалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 1600 (бер мең алты йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларына, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 800 (сигез йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

1) Урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау: торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлап тоту:
- урам яктырткычларын ремонтлау:
- урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү, яктырткычлар сатып алу;
- Кооператив урамында урамнарны яктырту өчен электр линиясе урнаштыру;
2) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын,скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;
3) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру.
4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- Иске Карамалы авылы эчендәге юлларны кышкы көне карап тору: Кооператив, Игенче, Яшьләр, Яр буе урамнары ;
- Иске Карамалы авылы эчендәге юлларны җәйге вакытта карап тору: Игенче урамы, Яшьләр урамы, Яр буе урамы.
Игенче, Яшьләр, Яр буе урамнарын хезмәтләр өчен килешү төзеп грейдирлау;
-Кооператив урамындагы юлда асфальт чокырларын ремонтлау;
- юл буендагы үләннәрне чабу;
5) Торак пункт территориясен төзекләндерү:

- парк өчен эскәмияләр ясау;
- халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу;
6) Традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар кору:
- Иске Карамалы авылы зираты коймасын буяу;
- Иске Карамалы авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу;
- Иске Карамалы авылы зиратлары территориясендә үлән чабу;
7) Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү:
- рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 424 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 216.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
Гражданнар җыенында катнашкан 216 кеше «РИЗА» позициясе өчен,
0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:
1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Иске Карамалы торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Иске Карамалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 1600 (бер мең алты йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларына, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 800 (сигез йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

1) Урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәлөнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау: торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлап тоту:
- урам яктырткычларын ремонтлау:
- урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү, яктырткычлар сатып алу;
- Кооператив урамында урамнарны яктырту өчен электр линиясе урнаштыру;
2) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын,скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;
3) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру.
4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- Иске Карамалы авылы эчендәге юлларны кышкы көне карап тору: Кооператив, Игенче, Яшьләр, Яр буе урамнары ;

- Иске Карамалы авылы эчендәге юлларны җәйге вакытта карап тору: Игенче урамы, Яшьләр урамы, Яр буе урамы.
Игенче, Яшьләр, Яр буе урамнарын хезмәтләр өчен килешү төзеп грейдирлау;
-Кооператив урамындагы юлда асфальт чокырларын ремонтлау;
- юл буендагы үләннәрне чабу;
5) Торак пункт территориясен төзекләндерү:
- парк өчен эскәмияләр ясау;
- халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу;
6) Традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар кору:
- Иске Карамалы авылы зираты коймасын буяу;
- Иске Карамалы авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу;
- Иске Карамалы авылы зиратлары территориясендә үлән чабу;
7) Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү:
- рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Карамалы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Кәримов